**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 29 июль | № 550

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карары белән расланган Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү турында» 2012 ел, 7 март, 188 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 29 май, 429 нчы, 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче, 2013 ел, 12 март, 157 нче, 2013 ел, 31 октябрь, 828 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Айлык акчалата түләүне бирү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме «Аз керемле дип тану һәм дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең керемен һәм җан башына уртача керемне һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләү тәртибе турында» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 5 – 14 статьяларында билгеләнгән кагыйдәләр буенча, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 ел, 20 август, 512 нче карары белән расланган Дәүләт социаль

ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең җан башына уртача керемен һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен исәплләгәндә исәпкә алынган керемнәр төрләре исемлегендә күрсәтелгән керемнәр төрләрен исәпкә алып, исәпләнелә.

Айлык акчалата түләүне билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме барлык кирәкле документлары белән айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза тапшырган айга кадәр булган соңгы өч календарь айга билгеләнә (алга таба – исәпләү чоры).

Гаиләнең җан башына уртача керемен билгеләгәндә аерым яки бергә яшәүләренә бәйсез рәвештә түләүне алучының ире (хатыны) булган гражданнарның керемнәре исәпкә алына.

Исәпләү чорында гаиләнең җан башына уртача кереме гаиләнең айлык берләштерелгән уртача керемен гаилә әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләнелә.

Исәпләү чорында гаиләнең айлык берләштерелгән уртача кереме барлык гаилә әгъзаларының уртача айлык керемнәре суммасына тигез.

Һәр гаилә әгъзасының уртача айлык кереме аның исәпләү чоры дәвамында алынган керемнәре суммасын әлеге исәпләү чорының бу керемнәрне алган айлары санына бүлү юлы белән билгеләнә.»;

6 пунктта «вәкиленә» сүзеннән соң «(әти-әнисенә, уллыкка (кызлыкка) алучыга, опекунга яки попечительгә) (алга таба – гариза бирүче).» сүзләрен өстәргә;

Нигезләмә тексты буенча «Үзәкнең филиалы» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Үзәкнең бүлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Айлык акчалата түләү билгеләү өчен гариза бирүче яки гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән зат гариза бирүченең яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе бүлегенә түбәндәге документларны тапшыра:

айлык акчалата түләү билгеләү турында гаризаны;

«Татарстан Республикасы буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесе (алга таба - медик-социаль экспертиза бюросы) биргән инвалид баланың даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булуы турында билгеләнгән формадагы белешмәне яисә инвалид баланың үз-үзенә хезмәт күрсәтү сәләте өченче дәрәҗәдә чикләнгәнлеге хакында билгесе булган шәхси тернәкләндерү программасы күчермәсен;

гариза биргән айга кадәрге өч айда һәр гаилә әгъзасының керемнәрен раслаган документларны;

вәкаләтле затлар өчен ышанычнамәне.

Гариза биргәндә гариза бирүче яки ул вәкаләтләр биргән вәкаләтле зат паспортын (аны алыштырган документны) күрсәтә һәм кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын бирә.

Әгәр документлар күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланмаган булса, алар төп нөсхәләре белән бергә бирелә һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңарга теркәлә торган документлар күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган булырга тиеш.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Үзәк бүлеге ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати багланышлар системасын кулланып, электрон формада айлык акчалата түләү бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге белешмәләрне ала:

бала тууны (уллыкка (кызлыкка) алуны) дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләрне;

инвалид балага опека (попечительлек) билгеләү турында белешмәләрне;

инвалид баланы тәрбиягә алган гаиләгә бирү турында белешмәләрне;

гариза бирүченең гаилә составы турында белешмәләрне;

хезмәткә яраксыз гражданнарны тәрбияләүне гамәлгә ашырган затларга билгеләнгән компенсация түләүләрен законлы вәкиле алуны раслаган белешмәләрне;

халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органыннан эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм бүтән түләүләр) алу һәм аларның күләме турында белешмәләрне;

Россия Федерациясе Пенсия фонды тормышка ашыра торган пенсия һәм бүтән социаль түләүләр алу һәм аларның күләме турында белешмәләрне;

социаль яклау органыннан социаль түләүләр алу һәм аларның күләме турында белешмәләрне.

Гариза бирүче яки гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән зат үз башлангычы белән Үзәк бүлегенә әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырырга хокуклы.»;

10 пунктта «(ярдәменә, күзәтүенә)» сүзләреннән соң «яисә инвалид баланың үз-үзенә хезмәт күрсәтү сәләте өченче дәрәҗәдә чикләнгәнлеге хакында билгесе булган шәхси тернәкләндерү программасына.» сүзләрен өстәргә;

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Айлык акчалата түләү алу өчен кирәкле гариза һәм документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Электрон документлар рәвешендә тапшырылган гариза һәм документлар (белешмәләр) Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән имзаланалар һәм электрон күчерү җайланмасы һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми кулланылыштагы мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләрне кулланып, тапшырылалар.

Айлык акчалата түләү алу өчен кирәкле гаризаны һәм документларны (белешмәләрне) электрон документлар рәвешендә тапшыру мондый гариза бирүченең айлык акчалата түләү алу максатларында үзенең шәхси мәгълүматларын эшкәртергә ризалыгына тәңгәл була.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\550.doc